ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әтнә муниципаль районы
Күәм авыл җирлеге

422740, Әтнә муниципаль районы
Күәм авылы, Х.Такташ урамы, 1 йорт 1003 б
тел. 3-63-39, факс 3-63-39

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Атнинский муниципальный район
Кубянское сельское
поселение

422740, Атнинский муниципальный район
с.Кубян, ул. Х.Такташа, 1, пом.1003
тел. 3-63-39, факс 3-63-39

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 ноябрь 2025 ел. № 8

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Җилгелде торак пунктында «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Җилгелде торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 1 номерлы, “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Җилгелде торак пунктында халык җыены карары” турындагы 2025 елның 31 октябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. 2025 елнын 28 ноябрендә «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Җилгелде торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 1 номерлы, “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Җилгелде торак пунктында халык җыены карары” турындагы 2025 елның 31 октябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

1.1.Билгеләргә:

-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Җилгелде торак пунктында «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Җилгелде торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 1 номерлы, “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Җилгелде торак пунктында халык җыены карары” турындагы 2025 елның 31 октябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Башкарма комитеты;

-гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 2025 елның 28 ноябре 10.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр;

үткәрү урыны – Җилгелде авылы, Җиләкле ур., 9 номерлы йорт яны;

1.2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 24 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Күәм авылы, Х.Такташ урамы, 1 йорт, 1003 б;

- сайлау хокукына ия булган Җилгелде торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;

-гражданнар җыены турында Җилгелде торак пункты халкына мәгълүмат стендлары аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итергә;

1.3. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Җилгелде торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 1 номерлы, "Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Җилгелде торак пунктында халык җыены карары" турындагы 2025 елның 31 октябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү белән килешәсезме:

1) Карарлар преамбуласында "2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә" сүзләрен "Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы №33-ФЗ Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә" сүзләренә алмаштырырга.

«РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталыда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы, Әтнә муниципаль районы, Җилгелде авылы, Җиләкле урамы, 9 нче йорт адресы буенча урнашкан стендка урнаштырырга.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Күәм авыл җирлеге башлыгы: Сәмигуллин Л.Ә.